





# Уйларым һәм хисләрем халкым белән...

***(1895- 1955)***


Казбек Гыйззәтов
ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ


ТАҖИ
ГЫЙЗЗӘТ
Пьесалар


Татарстан культура министрлыгы
Галиәсгар Камал исемендәге
Ленин орденлы
ТАТАР АКАДЕМИЯ
1976—1977 ел сезоны
ПРЕМЬЕРА
(Потоки)
драма 3 пәрдәдә
ТАССР КУЛЬТУРА МИНИСТРЛЫГЫ
ГАЛИӘСГАР КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ЛЕНИН ОРДЕНЛЫ
ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
1968/69 ел сезоны
Декабрь
24 25 27 31
ЯҢА СПЕКТАКЛЬ
Таҗи Гыйззәт
КЫЮ КЫЗЛАР
(Смелые девушки)
Комедия 3 пәрдәдә
Әсәрне сәхнәгә куючы — режиссер Марсель Сәлимҗанов
Художник — Мәәмүн Сутюшев
Композитор — Хөснул Вәлиуллин
Театрның баш режиссеры — Марсель СӘЛИМҖАНОВ
24 25 27 31
Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры
Таҗи Гыйззәт
Кыю кызлар
Комедия 3 пәрдәдә
Режиссер — М. Сәлимҗанов
Художник — М. Сутюшев
Композитор — Х. Вәлиуллин
ЛЕНИН ОРДЕНЛЫ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ОРДЕНА ЛЕНИНА ТАТАРСКИЙ АКАДЕМИЧЕСКИЙ ТЕАТР
ҖӘЙГЕ ГАСТРОЛЬЛӘР
КАЗАКЪ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ БИНАСЫНДА
Таҗи Гыйззәт
ЧАТКЫЛАР
Драма 3 пәрдә, 5 күренештә
Режиссер — Ширьяздан САРЫМСАКОВ
Художник — Әнәс ТУМАШЕВ





1925 нче елда Таҗи Гыйззәт азатлык көрәшенә багышланган “Наемщик” әсәрен яза.

Аның тарихы бик кызык була. Һәр спектакльны куйганда күршеләрдән, таныш-белешләрдән кием, өй җиһазлары җыя торган булганнар. Таҗи Гыйззәт күп очракта бар әйберне извозчик Кәлимуллалардан ала торган була. Әйбер биргән кеше театрга бушлай кергән. Шулай бер спектакальдан соң Кәлимулла агай Таҗи Гыйззәткә: “нигә син наемщиклар турында да кәмит язмыйсың?” – ди.
Ул вакытта Таҗи Гыйззәт наемщиклар турында ишеткәне була. Бигрәк тә әнисеннән берәр нәрсә сорап аптыратса, ул ана, “Әллә син наемщикмы?” – дип сорый торган булган. Шулай итеп Таҗи Гыйззәтнең күңелендә кешеләрне аптыратучы образ килеп баса. Кәлимулла абзыйның кызыклы хәлләрен дә өстәгән “наемщик” образы туа.
Ул башта өч пәрдәле Иманкол мулла өендә бараторган комедия була. Бик күп тапкырлар куела. Ә тора-бара яңа образлар өстәлеп музыкаль драмага әйләндерелә.

# “Наёмщик”






Вальс ("**Наемщик**" музыкаль драмасыннан) .



*Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик» музыкаль драмасы буенча куелган спектакльдән. Батырҗан ролендә С. Айдаров. 30-нчы еллар башы.*



*Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик» музыкаль драмасы буенча куелга спектакльдан. Салих Сәйдәшев музыкасы. Иманкол мулла ролендә — Зәйни Солтанов, мулланың беренче хатыны Миңсылу ролендә — Н. Таҗдарова, кече хатыны Зөбәрҗәт ролендә — Сара Садыкова. 30нчы еллар башы.*

С. Сәйдәшев «Наёмщик» ны операга кадәр үстермәкче була, ләкин хыялы тормышка ашмый.

Казанда 1928 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала.
Режиссёр — Сөләйман Вәлиев-Сульва (*1899*-*1956*).
Сәхнә бизәлеше — Петр Сперанский (*1891*-*1964*).
Либретто — Тажи Гыйззәт.
**Баш рольләрдә**[үзгәрту | вики-текстны үзгәрту]
*Батырҗан* — Ситдыйк Айдаров (*1895*-*1938*).
*Гөлйөзем* — Рокыя Кушловская (*1901*-*1986*).
Бүтән рольләрдә Зәйни Солтанов (*Иманкол*), Хәлил Әбҗәлилов, Габдулла Насыйбуллин, Хәким Сәлимҗанов (*Әскәр*), Гөлсем Болгарская (*Миңсылу*), Казан театр техникумы студентлары уйный.

Спектакльне 1931 (*режиссеры* Сөләйман Вәлиев-Сульва), 1941 (*режиссеры* Кәшифә Тумашева) елларда Татар дәүләт академия театрында яңартып куялар.
Соңрак М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында музыкаль драма буларак уйнала.
1950 елда композитор Александр Ключарев опера итеп эшли.

2016 елда Казан консерваториясенең опера студиясе (*җитәкчесе* Әлфия Җаббарова) Казанның С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында әсәрне концерт башкаруында куйды. Спектакльдә «Tatarica» оркестры (*җитәкчесе* Ринат Халитов), Казан музыка көллиятенең татар хоры (*җитәкчесе* Венера Гәрәева) катнашты.
Режиссер — Фәрит Бикчәнтәев.

**Төп партияләрне башкаручылар**[үзгәртү | вики-текстны үзгәртү]

*Батырҗан* — Филүс Каһиров
*Гөлйөзем* — Айгөл Хәйри



